Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Кузайкино авыл Советы

КАРАР

12 май 2025 ел №110

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кузайкино авыл Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кузайкино авыл җирлеге территориясендә җир салымы турында» 2013 елның 25 ноябрендәге 79 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Кузайкино авыл җирлеге Уставының 28 статьясы нигезендә, Әлмәт шәһәре прокуратурасының 06 мартыдагы 2025 ел 02-01-24 нче номерлы протестын карап

Кузайкино авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кузайкино авыл Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кузайкино авыл җирлеге территориясендә җир салымы турында»2013 елның 25 ноябрендәге 79 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кузайкино авыл Советының 2014 елның 19 ноябрендәге 115 номерлы, 2015 елның 05 маендагы 135 номерлы, 2020 елның 12 маендагы 115 номерлы, 2020 елның 19 ноябрендәге 7 номерлы, 2023 елның 14 декабрендәге 81 номерлы, 2024 елның 16 июлендәге 90 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктның өченче һәм дүртенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-Торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары билгән (торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган җир кишәрлеге өлешеннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата 0,3 процент, әлеге абзацта күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган җир кишәрлекләреннән һәм һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган җир кишәрлекләреннән тыш;

-Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яисә яшелчәчелек өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә, шулай ук «Гражданнар тарафыннан бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата 0,3 процент, һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән әлеге абзацта күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән тыш»;

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Кузайкино авылы, Совет урамы, 26 йорт торак пункт

территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгәннән соң үз көченә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Кузайкино авыл
җирлеге башлыгы В.И. Андреянов